**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**К А Р А Р**

«18» март 2022 ел № 2/1

**«Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында» Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 августындагы 41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше һәм 5 статьясы 1.3 өлеше, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. «Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында» Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 августындагы 41 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен район Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне каралга тәкъдим итәргә:

- салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү объектларына концессион килешү төзүгә уртак конкурс үткәрүне оештыру;
- муниципаль милекне арендага бирү һәм милекче кушуы буенча концессиягә тапшыруны оештыру.

2. Әлеге карарны Кече Шилнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов